ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СОБОЛЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.7, с. Шеланга,
422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
СОБОЛЕВСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Совет ур., 7 нче йорт, Шеланга авылы,
422577

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.11.2020 ел. Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48, № 23

с. Соболевсое

Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге Кармышиха авылы гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябреннән 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56нчы ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Соболевское авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге Кармышиха авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020нче елның 10нчы декабренә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2021нче елда Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге Кармышиха авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- су башнясы өчен савыт алу

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Халык җыенын Кармышиха авылы, Центральная урамы, 5нче йорт янында 11.00 сәгатьтә кибет бинасында үткәрергә.

4. Җыенны оештыручы итеп Соболевский авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге башлыгы О. Н. Майорова